**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

2017 ел, 20 июнь № 397

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә Татарстан Республикасында транспорт чараларының аерым төрләре мониторингының бердәм системасы турында» 2010 ел, 22 сентябрь, 754 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә Татарстан Республикасында транспорт чараларының аерым төрләре мониторингының бердәм системасы турында» 2010 ел, 22 сентябрь, 754 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» 2007 ел, 14 ноябрь, ПУ-610 нчы Указы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 ел, 6 декабрь, ПУ-1115 нче Указы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы чикләрендә елгалар акваторияләрендә һәм сусаклагычларда гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруны гамәлгә ашыручы суднолар.»;

5 нче пунктның дүртенче абзацында «транспорт чаралары,» сүзләреннән соң «суднолар, шул исәптән Татарстан Республикасы чикләрендә елгалар акваторияләрендә һәм сусаклагычларда гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруны гамәлгә ашыручы,».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\397.doc